АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**« 22 » декабрь 2015 г.** № 160/2лс

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе турында**

Татарстан Республикасының 2003 ел 12 маендагы №16-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында”гы Законның 23 маддәсе нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау Тәртибен расларга.

2. Матди-техник тәэмин итү секторының өлкән белгеченә гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне елга ике тапкыр, яртыеллыкның ахыргы аеннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр анализларга.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү секторы мөдиренә яртыеллыкның ахыргы аеннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр анализны Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И. Минуллина

Документ создан в электронной форме. № 01/228 от 30.01.2016. Исполнитель: Карпов О.А.
Страница 4 из 7. Страница создана: 29.01.2016 13:19
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
22.12.2015да №160/2лс
Боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының 2003 ел 12 маендагы №16-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында"гы Законының 23 маддәсен үтәү максатында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына (алга таба - Агентлык) гражданнар һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба - мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау тәртибен билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау эше матди-техник тәэмин итү секторы (алга таба - Сектор) тарафыннан электрон документ әйләнеше һәм әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларындагы мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Җитәкчегә, җитәкченең беренче урынбасарына, җитәкче урынбасарына (алга таба – Агентлык җитәкчелеге, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләтле вәкил) шәхси кабул итү вакытында кергән мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат Секторга гражданнарны Агентлык җитәкчелегенең шәхси кабул итүенә теркәгән белгеч тарафыннан тапшырыла.

4. Урыннарда кабул итү вакытында кергән мәгълүматны Секторга массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү секторы хезмәткәрләре тапшыра.

5. Анализ ясаганда кергән, бүтән адреска күчереп җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр исәбе турындагы, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләр турындагы, гражданнарны кабул итүнең урыны, көне, сәгате, шәхси кабул ителгән гражданнар исәбе, гражданнарны шәхси һәм урыннарда кабул итү буенча вәкаләтле вәкилләр турындагы, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәсендә күрелгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар (булган очракта) турындагы мәгълүмат өйрәнелә.

6. Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан Секторга яртыеллыкнын ахыргы аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр тапшыра.

7. Матди-техник тәэмин итү секторының өлкән белгече 2 пунктта күрсәтелгән, шулай ук Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары буенча кабул ителгән мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлауны ике эш көне дәвамында башкара һәм анализны Агентлык җитәкчесенең беренче урынбасары белән килештерә.

Документ создан в электронной форме. № 01/228 от 30.01.2016. Исполнитель: Карпов О.А.
Страница 5 из 7. Страница создана: 29.01.2016 13:19
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

8. Мөрәҗәгатьләр анализы Агентлыкның рәсми сайтына урнаштыру өчен массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү секторына җибәрелә. Анализ Агентлыкның рәсми сайтында яртыеллыкның ахыргы аеннан соң килүче айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

9. Гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр анализы Агентлыкта ачык мәгълүмат булып санала һәм Агентлыкның рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) ирекле кулланылышта тора.

Документ создан в электронной форме. № 01/228 от 30.01.2016. Исполнитель: Карпов О.А.
Страница 6 из 7. Страница создана: 29.01.2016 13:19
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН